| СОВЕТ<br>Новобизякинского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Яңа Бәзәкә авыл җирлеге<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01.10.2018 Яңавыл авылы № 46-1

Яңа Бәзәкә авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Яңа Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 10, 11 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 909 нчы карары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 2018 елның 28 августындагы 44-3 номерлы карары, Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 28 августындагы 8 номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Советы **карар бирде**:

1.2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге территориясендә

гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2.Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:
I һәм II группа инвалидлар һәм өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан (тиешле документлары булган очракта), Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылучылардан, ректән мәхрүм ителгәннәрдән кала, Яңа Бәзәкә авыл җирлегендә теркәлгән, җирле референдумда катнашырга хокукы булган һәр гражданга 2019 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:
1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә территорияне төзекләндерү:
- Халыкның һәм корылмаларның иминлегенә янаучы агачларны кисү.
2. Су белән тәэмин итү өчен материаллар сатып алу,ремонт, хезмәт күрсәтү.
3. Күмү урыннарын оештыру һәм карап тоту:
- Вольный Труд поселыгы зират коймасын ремонтлау.

ӘЙЕ ЮК».

3.Әлеге карарны Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе М.М. НОГМАНОВ